СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
«29» июня 2022 г.

**КАРАР**
№49

**Милеккә салым турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, "Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында" 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле физик затлар милкенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын күләмдә билгеләргә:

2.1. 0,1 % карата:

- әлеге пунктның 2.4 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннарга;
- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларына ;

2.2. 0,2 % карата:

- фатирларларга, фатирларның өлешләренә;
-бүлмәләргә;

2.3. 0,3 % карата:

- торак йортларга, торак йортларның өлешләренә;
- төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына, әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса;
- составына бер генә булса да торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар төзү;

2.4. 2% әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата, әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата.;

2.5. Башка салым салу объектларына карата 0,5%.

2.6.Ике фатирдан торган күп фатирлы йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрына салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташламалар билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.
Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 ноябрендәге 111 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының http://baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә урнаштырылган мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы халыкка игълан итәргә.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
6. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш. В. Низамиев